| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КЕРЛИГАЧСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КИРЛЕГӘЧ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 2 октябре № 25

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 32 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 32 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

10.1.3 пунктның 6нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслый торган документ;»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск районы Кирлегәч авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында “Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Кирлегәч авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Совет Рәисе С.Р.Сәлахова